ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 20 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 өлешнең 1 пунктында «арендалана торган» сүзләреннән соң «күчемле һәм» сүзләрен өстәргә;

2) $4^1$ өлештә «арендалана торган» сүзләреннән соң «күчемле һәм» сүзләрен өстәргә;

3) түбәндәге эчтәлектәге $4^3$ өлеш өстәргә:
«$4^3$. Татарстан Республикасы милкендәге арендалана торган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан, мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырып, «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159- ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә сатып алына торган мөлкәт өчен кичектереп түләү срогы күчемсез мөлкәт өчен сигез елдан һәм күчемле мөлкәт өчен өч елдан гыйбарәт була. Арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектына сатып алына торган арендаланучы мөлкәт өчен түләү тәртибен (берьюлы яисә кичектереп түләү),

шулай ук әлеге өлеш нигезендә билгеләнгән чикләрдә кичектереп түләү срогын сайлау хокукы бирелә.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы $4^3$ өлеше нигезләмәләренең (әлеге Закон редакциясендә) гамәлдә булуы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары белән элегрәк төзелгән Татарстан Республикасы милкендәге арендалана торган мөлкәтне сату-алу килешүләреннән килеп чыккан хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2023 ел, 03 май
№ 40-ТРЗ